РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘМӘШИР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2025 ел Мәмәшир авылы № 3

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, гавами тыңлаулар уздыру юлы белән

КАРАР БИРӘМ:

1. Кукмара муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү турында» 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы карарында белдерелгән инициативаны карау турында гавами тыңлауларны 1 нче кушымта нигезендә 2025 елның 5 декабренә билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Мамашир авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын билгеләргә, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы, 29б йорт. Үткәрү вакыты: 09 сәгать 00 минут.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Әхмәтҗанов Илгиз Габтеләхәт улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

Насыйбуллин Ринат Раян улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Ваһапов Фәрит Вәгыйзь улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Шаһиев Илшат Илһаметдин улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Шәяхкәмов Хәмит Котдус улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты.

4. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе СОСТАВын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

5. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру барышында идентификацияләнгән гавами тыңлауларда катнашучылардан язма яисә телдән, язма формада авторның ФИА һәм аның адресын күрсәтеп, Мәмәшир авыл җирлеге администрациясе адресына (Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр ур., 29Б й.) (2025 елның 10 ноябреннән 2025 елның 5 декабренә кадәр эш көннәрендә 09:00 дән 16: 00 гә кадәр) яисә Mam.kuk@tatar.ru электрон адресына кабул ителә.

6. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокуккы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы,29б йорт, шәхсән яисә почта аша (конвертта «гавами тыңлаулар» тамгасы белән), 884364-36604.


7. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 3нче номерлы карарына 2нче кушымта




**Условные обозначения**

- граница Республики Татарстан
- граница муниципального района
- граница Мамаширского сельского поселения
- населенные пункты
- административный центр поселения
- территории, исключаемые из состава Кукморского муниципального района и Мамаширского сельского поселения

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының
2025 елның 10 ноябрендәге
3 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе СОСТАВЫ

Әхмәтҗанов Илгиз Габтеләхәт улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

Насыйбуллин Ринат Раян улы– Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Ваһапов Фәрит Вәгыйзь улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Шаһиев Илшат Илһаметдин улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Шәяхкәмов Хәмит Котдус улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты